**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Яңасала  авыл җирлеге**
**муниципаль берәмлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**“19”май 2023 ел** **№78**

**2023 елда «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл жирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендэ, "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар кабул итте:

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары белән «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль берәмлек органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин.

2.Әлеге карарның 1 пункты «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яңасала авыл җирлеге башлыгы И.Х.Шиһабеевка йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районыны
Яңасала  авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге Советы рәисе И.Х.Шиһабеев